КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 9 ноябрь г.Казань № 1002

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 ноябрь, 1048 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 33 нче; 2020 ел, 26 февраль, 147 нче; 2020 ел, 27 июль, 626 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны | Программаны финанслауның гомуми күләме 128 731 333,93 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: |

финанслау күләмнәре

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Җәлеп итәргә планлаштырыла торган түбәндәгеләр акчасы | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | федераль бюджет | Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе | «Моно-шәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы | җирле бюджетлар | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2020 | 18 898 518,22 | 10 173 229,94 | 3 642 913,6 | 71 660,6 | 149 972,8 | 1 072 931,0 | 3 787 810,28 |
| 2021 | 21 711 578,28 | 15 275 898,2 | 1 574 938,8 | - | - | 1 072 931,0 | 3 787 810,28 |
| 2022 | 22 284 644,78 | 15 494 239,1 | 1 929 664,4 | - | - | 1 072 931,0 | 3 787 810,28 |
| 2023 | 21 556 194,89 | 14 983 418,73 | 1 506 420,0 | - | - | 1 119 067,03 | 3 947 289,12 |
| 2024 | 22 864 994,16 | 15 699 191,69 | 1 884 990,0 | - | - | 1 167 186,92 | 4 113 625,55 |
| 2025 | 21 415 403,6 | 15 910 913,19 | - | - | - | 1 217 375,95 | 4 287 114,45 |
| Барысы | 128 731 333,93 | 87 536 890,85 | 10 538 926,8 | 71 660,6 | 149 972,8 | 6 722 422,9 | 23 711 459,97 |

Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программаның 2 бүлегендә:

илле өченче – илле алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү (модернизацияләү) өчен, шулай ук 3 һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрен мондый объектлар белән тәэмин итү өчен заемчылар тарафыннан Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча процентларны түләү чыгымнарын (чыгымнарының бер өлешен) каплау;

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында төзелгән җылылык белән тәэмин итү объектларын, үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су чыгару системаларын, мондый системаларның аерым объектларын булдыруга һәм (яки) реконструкцияләүгә (модернизацияләүгә) концессия килешүләре буенча концедент түләү чыгымнарын (чыгымнарының бер өлешен) каплау;

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру);

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында федераль проект кысаларында 2021 елга кадәр (2021 елны кертеп) финанслануы гамәлгә ашырылган (мәктәпкәчә учреждениеләр, гомуми белем бирү учреждениеләре һәм сәламәтлек саклау учреждениеләренең) социаль инфраструктура объектларын төзү (реконструкцияләү), шулай ук территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында транспорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү), су белән тәэмин итү, су чыгару һәм җылылык белән тәэмин итү объектларын, шул исәптән магистраль челтәрләр төзү (реконструкцияләү).»;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны тормышка ашыруның фаразланган финанслар белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет, Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2020 – 2025 елларда Программаны финанслауның фаразланган гомуми күләме 128 731 333,93 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Җәлеп итәргә планлаштырыла торган түбәндәгеләр акчасы | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | федераль бюджет | Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе | «Моно-шәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы | җирле бюджетлар | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2020 | 18 898 518,22 | 10 173 229,94 | 3 642 913,6 | 71 660,6 | 149 972,8 | 1 072 931,0 | 3 787 810,28 |
| 2021 | 21 711 578,28 | 15 275 898,2 | 1 574 938,8 | - | - | 1 072 931,0 | 3 787 810,28 |
| 2022 | 22 284 644,78 | 15 494 239,1 | 1 929 664,4 | - | - | 1 072 931,0 | 3 787 810,28 |
| 2023 | 21 556 194,89 | 14 983 418,73 | 1 506 420,0 | - | - | 1 119 067,03 | 3 947 289,12 |
| 2024 | 22 864 994,16 | 15 699 191,69 | 1 884 990,0 | - | - | 1 167 186,92 | 4 113 625,55 |
| 2025 | 21 415 403,6 | 15 910 913,19 | - | - | - | 1 217 375,95 | 4 287 114,45 |
| Барысы | 128 731 333,93 | 87 536 890,85 | 10 538 926,8 | 71 660,6 | 149 972,8 | 6 722 422,9 | 23 711 459,97 |

Программа юнәлешләре буенча финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләреннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Программаның барлык чыганаклар исәбеннән ресурслар белән тәэмин ителеше һәм Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының фаразланган бәясе бу Программага теркәлгән кушымтада китерелә.»;

Программага теркәлгән кушымтада:

«Торак төзелешен үстерү программаларын стимуллаштыру» юлының 12 графасында «234 001,9 ТРБ» һәм «997 586,7 ФБ» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «462 001,8 ТРБ» һәм «1 969 586,7 ФБ» сүзләренә алыштырырга;

«Сууткәргеч-канализация хуҗалыгы предприятиеләренең пычранган агызыла торган сулары өлешен киметү» юлының 12 графасында «261 807,7 ТРБ» һәм «716 225,2 ФБ» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «305 139,0 ТРБ» һәм «1 300 855,5 ФБ» сүзләренә алыштырырга;

«Программа буенча барлыгы, шул исәптән:» юлының 12 графасында «17 070 556,68» саннарын «18 898 518,2» саннарына алыштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлының 12 графасында «9 901 898,7» саннарын «10 173 229,9» саннарына алыштырырга;

«федераль бюджет» юлының 12 графасында «2 086 283,3» саннарын «3 642 913,6» саннарына алыштырырга;

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасында:

3 нче кушымтада:

1 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Кагыйдәләр вәкаләтле оешмалар һәм «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыруда катнашу өчен сайлап алынган банклар аша торак сатып алу яки индивидуаль торак йорт төзү өчен яшь гаиләләргә социаль түләүләр (алга таба – 1 нче ярдәмче программа, социаль түләүләр) бирү тәртибен билгели; алар түбәндәгеләргә җибәрелергә мөмкин: торак урын сату-сатып алу шартнамәсе (алга таба – торак урын шартнамәсе) (сату-сатып алу шартнамәсенә түләү беренчел торак базарында торак урын сатып алу өчен вәкаләтле оешма белән шартнамә бәясе составында карала торган акчадан тыш) өчен түләүгә; төзелеш подрядының торак йорт төзелешенә шартнамәсе бәясе өчен түләүгә; яшь гаилә яки яшь гаиләдә ире яки хатыны торак, торак-төзелеш, торакка акча җыю кооперативы (алга таба – кооператив) әгъзасы булган очракта, пай кертемен тулы күләмдә түләү исәбенә соңгы түләүне гамәлгә ашыруга, аны түләп бетергәннән соң торак урын бу яшь гаилә милкенә күчә; торак, шул исәптән торак ипотека кредитын яки сату-сатып алу яисә торак йорт төзү шартнамәсе буенча торак урын сатып алу өчен торак заемын (алга таба – торак кредиты) алганда беренчел кертемне түләүгә; вәкаләтле оешма белән яшь гаилә мәнфәгатьләрендә торакның беренчел базарында торак урын сатып алу шартнамәсе өчен түләүгә, шул исәптән торак урынны сату-сатып алу шартнамәсе бәясенә түләүгә (шартнамәдә бу каралган очракларда) һәм (яки) әлеге оешманың хезмәт күрсәтүләре өчен түләүгә; торак сатып алуга яки торак йорт төзүгә торак, шул исәптән торак ипотека кредиты яки торак заемы алганда беренчел кертемне түләүгә; торак урын сатып алуга яки торак йорт төзүгә торак кредиты буенча яки торак урын сатып алуга яки торак йорт төзүгә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) буенча төп бурыч суммасын (төп бурыч суммасының бер өлешен) (әлеге торак кредитлары йә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредитлар (заемнар) буенча йөкләмәләрнең үтәлешен үз вакытында башкармаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш) түләп бетерүгә (алга таба – кредитлар буенча бурычны түләп бетерү); «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статья-сындагы 4 өлешенең 5 пунктында билгеләнгән өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү шартларының берсе үз эченә алган торак урынны өлешле төзү объекты буларак күздә тота торган өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе (алга таба – өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе) бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашучы тарафыннан өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе (алга таба – өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе) бәясенә

түләүгә; өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләү, өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләү өчен беренчел кертемне түләүгә; өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә торак кредиты буенча йә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) буенча төп бурыч суммасын (төп бурыч суммасының бер өлешен) һәм процентларны (әлеге торак кредитлары йә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредитлар (заемнар) буенча йөкләмәләрнең үтәлешен үз вакытында башкармаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш) түләп бетерүгә.»;

5 нче пунктның «в» пунктчасындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшь гаилә таныклык бирелгән көннән һәм аның банк счетына сатып алына торган торак урын өчен түләү, торак кредитын, шул исәптән торак ипотека кредитын алганда беренчел кертемне яки торак урын сатып алу яки торак йорт төзү заемына, вәкаләтле оешма белән шартнамәгә түләү, ипотека кредитлары яки торак сатып алу яки торак йорт төзү заемнары буенча бурычның төп суммасын түләп бетерү һәм процентларны түләү, өлешле төзелештә катнашу шартнамәсенә, өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсенә түләү, йә кооператив әгъзасының пай кертеменең калган өлешен түләү исәбенә кергән акча банк тарафыннан күчерелү турында счет белән эш итүченең боерыгын банк үтәгән вакытка кадәр 1 нче ярдәмче программада катнашучы итеп таныла.»;

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Яшь гаилә өчен элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә социаль түләү кулланылган очракта торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләгәндә йөкләмәләре тулысынча үтәлмәгән яисә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) буенча йөкләмәләр үтәлмәгән торак кредиты акчасы исәбеннән сатып алынган (төзелгән) торак урын исәпкә алынмый.»;

9 нчы пунктның бишенче абзацында «торак йорт төзүгә (башка процентлардан тыш)» сүзләрен «торак йорт төзүгә, элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә (башка процентлардан тыш)» сүзләренә алыштырырга;

15 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Бу Кагыйдәләрнең 1 нче пункты нигезендә социаль түләүне файдалану максатларында 1 нче ярдәмче программада катнашу өчен (социаль түләүне кредит буенча бурычны түләп бетерү өчен, өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә торак кредиты буенча йә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) буенча төп бурыч суммасын (төп бурыч суммасының бер өлешен) түләп бетерү һәм процентларны түләү (әлеге торак кредитлары йә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредитлар

(заемнар) буенча йөкләмәләрнең үтәлешен үз вакытында башкармаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш) өчен файдаланудан тыш) яшь гаилә даими яшәү урыны буенча җирле үзидарә органына түбәндәге документларны тапшыра:»;

тугызынчы абзацта «балигъ» сүзен төшереп калдырырга;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Социаль түләүне кредит буенча бурычны түләп бетерү өчен, өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә торак кредиты буенча йә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) буенча төп бурыч суммасын (төп бурыч суммасының бер өлешен) түләп бетерү һәм процентларны түләү (әлеге торак кредитлары йә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредитлар (заемнар) буенча йөкләмәләрнең үтәлешен үз вакытында башкармаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш) өчен файдалану максатларында яшь гаилә даими яшәү урыны буенча җирле үзидарә органына бу Кагыйдәләрнең 15 нче пунктындагы «б» – «г», «е» һәм «з» пунктчалары нигезендә документларны, түбәндәге документларны тапшыра:

торак кредиты акчасын кулланып сатып алынган (төзелгән) торак урынга (торак йортка) хокуклар турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (өземтәләр) яки торак йорт төзелеп бетмәгәндә төзелеш подряды шартнамәсе яки торак йорт төзү чыгымнарын раслый торган башка документлар (алга таба – төзелеш документлары);

өлешле төзелештә катнашу шартнамәсенең күчермәсен йә, социаль түләүне өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә торак кредиты буенча йә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яки өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсе бәясен түләүгә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) буенча төп бурыч суммасын (төп бурыч суммасының бер өлешен) түләп бетерү һәм процентларны түләү (әлеге торак кредитлары йә элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредитлар (заемнар) буенча йөкләмәләрнең үтәлешен үз вакытында башкармаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш) өчен файдаланган очракта, өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларына ташлама бирү шартнамәсенең күчермәсен;

торак кредиты шартнамәсенең күчермәсен;

элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) шартнамәсенең күчермәсен – элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит (заем) буенча төп бурыч суммасын (төп бурыч суммасының бер өлешен) түләп бетерү һәм процентларны түләү өчен социаль түләүдән файдаланган очракта;

торак кредиты шартнамәсе төзелгән көнгә бу Кагыйдәләрнең 6 нчы пункты нигезендә торак урынына мохтаҗ яшь гаилә дип тануны раслый торган документ;

кредиторның (заемга бирүченең) түләп бетерү өчен социаль түләү кулланыла торган торак кредиты яки элегрәк бирелгән торак кредитын түләп бетерүгә кредит

(заем) буенча төп бурыч суммасының калган өлеше һәм тиешле кредитны кулланган өчен процентлар түләү буенча бурычлар суммасы турында белешмә кәгазен.»;

5 нче кушымтаның 10 нчы пунктында «балигъ» сүзен төшереп калдырырга;

«Торак» федераль проекты чараларын тормышка ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td>
<td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 431 588,52 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлык акча</th><th colspan="2">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2020</td><td>2 431 588,52</td><td>462 001,82</td><td>1 969 586,7</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>*</td><td>*</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>*</td><td>*</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>*</td><td>*</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>*</td><td>*</td><td>*</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>2 431 588,52</td><td>462 001,82</td><td>1 969 586,7</td></tr>
</table>
* Чараларны финанслау күләмнәре Россия Федерациясе субъектлары арасында субсидияләр бүлү нәтиҗәләре буенча ел саен билгеләнергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 3 нче ярдәмче программаның төп максатлары һәм бурычлары, чаралар, соңгы нәтиҗәләрнең тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары

3 нче ярдәмче программаның максаты – Татарстан Республикасында торак төзелеше күләмен арттыру.

3 нче ярдәмче программаның бурычы – торак төзелешен үстерү программаларын стимуллаштыру чараларын тормышка ашыру.

3 нче ярдәмче программа кысаларында торак төзелешен үстерү программаларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр алырга планлаштырыла, алар түбәндәгеләргә файдаланылырга мөмкин:

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү (модернизацияләү) өчен, шулай ук 3 һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрен мондый объектлар белән тәэмин итү өчен заемчылар тарафыннан Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча процентларны түләү чыгымнарын (чыгымнарының бер өлешен) каплау;

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында төзелгән җылылык белән тәэмин итү объектларын, үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су чыгару системаларын, мондый системаларның аерым объектларын булдыруга һәм (яки) реконструкцияләүгә (модернизацияләүгә) концессия килешүләре буенча концедент түләү чыгымнарын (чыгымнарының бер өлешен) каплау;

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру);

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында федераль проект кысаларында 2021 елга кадәр (2021 елны кертеп) финанслануы гамәлгә ашырылган (мәктәпкәчә учреждениеләр, гомуми белем бирү учреждениеләре һәм сәламәтлек саклау учреждениеләренең) социаль инфраструктура объектларын төзү (реконструкцияләү);

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында транспорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү);

территорияләрне үстерү проектларын гамәлгә ашыру максатларында су белән тәэмин итү, су чыгару һәм җылылык белән тәэмин итү объектларын, шул исәптән магистраль челтәрләрне төзү (реконструкцияләү).

3 нче ярдәмче программа кысаларында оештыру чаралары түбәндәгеләргә юнәлдереләчәк:

торак төзелешендә административ киртәләрне киметү өчен шартлар тудыруга, конкуренцияне үстерүгә һәм төзүчеләрнең кредит ресурсларыннан, шәһәр төзелеше һәм монополиягә каршы контроль өлкәсендә чараларны тормышка ашырудан файдалана алуын киңәйтүгә;

торак төзелешен тәэмин итү өчен кирәкле шәһәр округларының һәм шәһәр җирлекләренең коммуналь, транспорт һәм социаль инфраструктурасын комплекслы үстерүнең оештыру механизмнарын кертүгә булышлык күрсәтүгә;

проектларны тормышка ашыру өчен кредит һәм инвестиция чараларын җәлеп итүнең оештыру механизмнарын кертүгә.

Оештыру чаралары өстәмә бюджет акчасы бүлеп бирүне таләп итмәячәк.

3 нче ярдәмче программа 2020 – 2024 елларда тормышка ашырылачак.

3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру этаплары бүленми.

Программа чараларын тормышка ашыру 2024 ел йомгаклары буенча торак төзелеше күләмен елына 3,6 млн.кв.метрга кадәр арттырырга мөмкинлек бирәчәк.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 3 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 431 588,52 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы |
| 2020 | 2 431 588,52 | 462 001,82 | 1 969 586,7 |
| 2021 | * | * | * |
| 2022 | * | * | * |
| 2023 | * | * | * |
| 2024 | * | * | * |
| Барысы | 2 431 588,52 | 462 001,82 | 1 969 586,7 |

* Чараларны финанслау күләмнәре Россия Федерациясе субъектлары арасында субсидияләр бүлү нәтиҗәләре буенча ел саен билгеләнергә тиеш.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау, 3 нче ярдәмче программада катнашучы инвестиция проектларын финанслауда еллык гомуми ихтыяҗдан чыгып, Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу дәрәҗәсен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

1 нче кушымтада:

«Торак төзелешен үстерү программаларын тормышка ашыруга субсияләр алу» юлының 11 графасында «234 001,9 ТРБ» һәм «997 586,7 ФБ» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «462 001,8 ТРБ» һәм «1 969 586,7 ФБ» сүзләренә алыштырырга;

«Ярдәмче программа буенча барлыгы, шул исәптән:» юлының 11 графасында «1 231 588,6» саннарын «2 431 588,5» саннарына алыштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлының 11 графсында «234 001,9» саннарын «462 001,8» саннарына алыштырырга;

«федераль бюджет» юлының 11 графасында «997 586,7» саннарын «1 969 586,7» саннарына алыштырырга;

2 нче кушымтаны яңа редакциядә (кararга теркәлә) бәян итәргә;

«Иделне савыктыру» федераль проекты чараларын тормышка ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – 7 нче ярдәмче программа):

7 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмн» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләме

7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 9 084 698,52 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы |
| 2020 | 1 605 994,52 | 305 139,02 | 1 300 855,5 |
| 2021 | 1 715 783,7 | 325 998,9 | 1 389 784,8 |
| 2022 | 2 061 180,3 | 391 624,3 | 1 669 556,0 |
| 2023 | 1 564 470,0 | 297 250,0 | 1 267 220,0 |
| 2024 | 2 137 270,0 | 406 080,0 | 1 731 190,0 |
| Барысы | 9 084 698,52 | 1 726 092,22 | 7 358 606,3 |

| | |
|---|---|
| | Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

1 бүлекнең 2 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

2019 елда төзелгән яки реконструкцияләнгән (модернизацияләнгән) объектлар исемлеге

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Капиталь төзелеш объектының / чараның исеме | Егәрлеге | Финанслау, мең сум (агымдагы бәяләрдә) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барлык акча | шул исәптән | |
| | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы |
| 1. | Әгерҗе муниципаль районы | ТР Әгерҗе муниципаль районының Кызыл Бор авылында биологик чистарту корылмалары төзү | 1 тәүлеккә 150 куб.метр | 42 786,23 | 8 129,38 | 34 656,84 |
| 2. | Алексеевск муниципаль районы | ТР Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында чистарту корылмалары төзү | 1 тәүлеккә 1 200 куб.метр | 106 222,11 | 20 182,20 | 86 039,91 |
| 3. | Зәй муниципаль районы | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Поповка авыл җирлеге чистарту корылмалары төзү | 1 тәүлеккә 600 куб.метр | 80 823,53 | 15 356,47 | 65 467,06 |
| 4. | Алабуга муниципаль районы | «Алабуга» СҖТ МИЗ һәм Алабуга шәһәренең көнкүреш һәм сәнәгать агызыла торган суларының район чистарту корылмаларын реконструкцияләү. I этап | 1 тәүлеккә 19 500 куб.метр | 735 723,37 | 139 787,44 | 595 935,93 |
| 5. | Тәтеш муниципаль районы | Тәтеш шәһәрендә яңгыр канализациясе булдыру | 1 тәүлеккә 3 020 куб.метр | 92 840,03 | 17 639,61 | 75 200,43 |
| 6. | Казан шәһәре | Казан шәһәренең Ветеринария академиясе районында су объектларына яңгыр канализациясе чыгу юлларында өске агызыла торган суларын чистарту корылмалары төзү | 1 тәүлеккә 650 куб.метр | 63 542,99 | 12 073,16 | 51 469,83»; |

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 7 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 9 084 698,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы |
| 2020 | 1 605 994,5 | 305 139,0 | 1 300 855,5 |
| 2021 | 1 715 783,7 | 325 998,9 | 1 389 784,8 |
| 2022 | 2 061 180,3 | 391 624,3 | 1 669 556,0 |
| 2023 | 1 564 470,0 | 297 250,0 | 1 267 220,0 |
| 2024 | 2 137 270,0 | 406 080,0 | 1 731 190,0 |
| Барысы | 9 084 698,5 | 1 726 092,2 | 7 358 606,3 |

Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

кушымтада:

башисемдә «кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алыштырырга;

«Суүткәргеч-канализация хуҗалыгы предприятиеләренең чистарту корылмаларын төзү (реконструкцияләү (шул исәптән реставрация элементлары белән) техник җиһазландыру)» юлының 11 графасында «261 807,7 ТРБ» һәм «716 225,2 ФБ» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «305 139,0 ТРБ» һәм «1 300 855,5 ФБ» сүзләренә алыштырырга;

«Ярдәмче программа буенча барысы, шул исәптән:» юлының 11 графасында «978 032,9» саннарын «1 605 994,5» саннарына алыштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлының 11 графасында «261 807,7» саннарын «305 139,0» саннарына алыштырырга;

«федераль бюджет» юлының 11 графасында «716 225,2» саннарын «1 300 855,5» саннарына алыштырырга;

2 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин